**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы №69 25 сентябрь 2017 ел

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Уразай авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартындагы 23-ФЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә «җирле референдум турында» ТРЗ, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетының «референдум үткәрү инициативасы турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 15 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл Советының «референдум үткәрү инициативасы турында»2017 елның 11 сентябрендәге 67 номерлы карарын карап,

Уразай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2017 елның 19 ноябренә Уразай авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга: «Сез 2018 елда Уразай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы ?
1) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр куюны, кече архитектура формаларын урнаштыруны һәм карап тотуны кертеп):
1.1 урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү,
1.2 агачларны кисү,
1.3 һәйкәлне ремонтлау;

2) җирлек халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру:
2.1 бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү,

2.2 музейны оештыру;
3) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
3.1 җирлек эчендәге юлларны кардан чистарту;

4) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру:
4.1 спорт залын ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис: А.М.Шәрифуллина

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы № 69 25 сентябрь 2017 ел.

Уразай авылы җирлеге биләмәсендә

узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Уразай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Уразай авылы башкарма комитетының 26 сентябрь 2016 елда чыккан 15 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Уразай авыл җирлеге Советының 26 сентябрь 2017 елда чыккан 67 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Уразай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Уразай авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 19 ноябрь 2017 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   “Сез, Уразай авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2018 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, I инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләрен урнаштыру, , кече архитектура формаларын карап тоту):
1.1 урам утларына техник хезмәт күрсәтү,
1.2 агач кистерү,
1.3 һәйкәл ремонтлау;

2) авыл халкынын ялын оештыру:
2.1 бэйрэмнэр оештыру һәм үткәрү,
2.2 музей оештыру;

3) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юллары эшчәнлеге:
3.1 авыл жирлеге юлларын кардан чистарту;

4) җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны оештыру очен шартлар тудыру , авыл жирлегендэ рәсми физкультура - сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру:
4.1 спорт залга ремонт.
ӘЙЕ ЮК

1. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
2. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: А.М.Шарифуллина